| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2023 Девәтернә авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 21 ноябрендә 09 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнеп, үз теләкләре буенча китүчеләр) һәм аларның гаилә членнарын (бергә яшәүче әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; дизель ягулыгы һәм май сатып алу; шартнамә буенча тракторист хезмәте өчен түләү);

- Гали авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу, урнаштыру; шартнамә буенча эшләр өчен түләү;

- Гали авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын һәм материалларны ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу, башка хезмәтләр;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү: запас частьлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм янгын сүндерү машинасы йөртүчесенең хезмәте өчен түләү;

- торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларны карап тоту, ремонтлау (Гали авылында Үзәк урамга җәю өчен вак таш сатып алу һәм җәю); кыш көне Гали авылы урамнарны кардан чистарту;

- Гали торак пунктында уңайлыклар булдыру (урамнарда чүп чабу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Гали авылында, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл янында мәйданчыкта уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Э.Э. ГАНИЕВ

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет Девятернинского сельского поселения
Девәтернә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002646
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ